КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 май г.Казань № 338

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2023 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карары белән расланган «2016 – 2023 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасына теркәлгән кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2023 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 10 июнь, 395 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 5 июнь, 342 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 650 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 911 нче; 2018 ел, 14 май, 363 нче; 2018 ел, 24 декабрь, 1211 нче; 2019 ел, 22 июль, 610 нчы; 2020 ел, 27 апрель, 343 нче; 2020 ел, 6 июль, 563 нче; 2020 ел, 19 декабрь, 1161 нче; 2021 ел, 6 март, 120 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2016 – 2023 елларга Татарстан Республикасында архив эшен үстерү» дәүләт программасына теркәлгән кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.4.3 пунктның1 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.3. Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында «Тарих фәннәре һәм бөтендөнья

мәдәни мирас югары мәктәбе» һәм «Халыкара мөнәсәбәтләр һәм көнчыгышны өйрәнү югары мәктәбе», Казан дәүләт мәдәният институтында «Китапханә-мәгълүмат эшчәнлеге һәм интеллектуаль системалары» юнәлешләре буенча белем алучыларга фәнни стипендияләр түләү»;

1.4.6 пунктның 1 графасында «бәйрәмен» сүзен «фестивален» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                   А.В.Песошин